2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2022 елның 8 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1 2023 елда гражданнардан үзара салым җыюны Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегенең Песәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 1000 сум күләмендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, I һәм II төркем инвалидларга, балигъ булмаган балалы гаиләләргә, көндезге уку рәвешендәге студентларга, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнарга әлеге түләүне 500 сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә.

2. Үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. юлларны кардан чистарту;
2. урам яктырткычларын урнаштыру.

3. Әлеге карарны Песәй авылындагы махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Песәй авыл җирлеге
башлыгы В.И. Мөхәммәтгалиев